

**Хәерле көн сиңа да,**
**Хәерле көн миңа да,**
**Хәерле көн безгә дә,**
**Хәерле көн сезгә дә.**

# Җөмлә кисәкләре



**Һавада тургай, ягъни сабанның сайрар кошы тавышы яңгырый.**

**Быел ул, бригадир кыз, тагын бүләкләнде.**

**Без җиләкле урынга – каенлы тау итәгенә барып җиттек.**

**Авылны яшелләндерүдә һәммәсе, аеруча яшьләр актив катнашты.**

**Өстәмә аныклык, төгәллек (пояснение) бирә торган сүзләр җөмләнең иярчен кисәге аныклагыч дип атала.**

**Һавада <u>тургай</u>, ягъни сабанның сайрар кошы тавышы яңгырый.**

**Быел <u>ул</u>, бригадир кыз, тагын бүләкләнде.**

**Без җиләкле <u>урынга</u> – каенлы тау итәгенә барып җиттек.**

**Авылны яшелләндерүдә <u>һәммәсе</u>, аеруча яшьләр актив катнашты.**

**Аныклагычны ияртеп килгән сүз аныкланмыш дип атала.**

**Аныклагыч астына дулкынлы ике сызык сызыла**


# Аныклагыч аныкланмышка
# 2 төрле юл белән бәйләнә:

1. Аныклаулы мөнәсәбәт (интонация)
2. Аныклаулы теркәгечләр ярдәмендә (ягъни, бигрәк тә, дөресрәге, аеруча, башкача әйткәндә, мәсәлән һ.б.)

**Җөмләдә ияртүче кисәктән соң килеп аңа өстәмә аныклык, төгәллек (пояснение) бирә торган сүзләр аныклагыч дип атала.**

**Шулай да егет түзде: сыкранмады, зарланмады, сер бирмәде.**
**Биредә, ягъни балалар янында, аңа аеруча күңелле иде.**
**Кешеләр, аеруча яшьләр, бәйрәмгә сөенәләр иде.**

**Аныклагыч аныкланмыш белән бер формада була.**



# Физкультминутка

Бергәләшеп без басыйк,
Бик зур түгәрәк ясыйк.
Кояшның җылы нурыннан
Йөрәкләргә көч алыйк.
Татулашыйк, дуслашыйк,
Шөгылебезне башлыйк.

**Җөмлә калыбы буенча дөрес итеп җөмлә төзе.**

**Без, анықлагыч, кайчан? кая бардык?**

**Сез, анықлагыч, кайчан? кая барачаксыз?**

**Безне, анықлагыч, кайчан? кая чакырдылар?**

**Алар, анықлагыч, кайчан? кая киттеләр?**

**1) Казан- киләчәк шәһәре. 2)Аның киләчәге зурдан.3) Шәһәрнең дан -шөһрәте еракларга, дөньяның бар почмагына таралды. 4)Әнә бит шәһәр 2013 нче елда Универсиада -спорт уеннары уздырды. 5)Бу хокукны, ягъни Универсиада уеннарын үткәрү хокукын, шәһәрем бик күп конкурентларын җиңеп яулап алды. 6) Шәһәребезгә дөньяның бик күп почмакларыннан, атап әйтсәк Америкадан, Бразилиядән, Италиядән, Кытайдан, Төркиядән кунаклар килде. 7) Универсиада вакытында 15 мең спортчы, 50 мең журналист, 50 мең турист кабул ителде. 8) Шәһәр көннән-көн үзгәрә бара. 9)Күп сандагы спорт комплекслары төзелә .**

**10) Шәһәремдә сәламәт яшәү рәвеше алып барыр өчен мөмкинлекләр арта.**

**В1-Тексттан аныклагычы булган җөмләләрне үсә бару тәртибендә яз.**
**В2-Аныклау интонациясе ярдәмендә бәйләнгән җөмләләрнең санын күрсәт.**
**В3 - 5 нче җөмләдәге аныкланмышны табып яз.**
**В4- 6 җөмләдә аныклагыч үзе аныклаган сүзгә нәрсә ярдәмендә бәйләнгән.**

**Җаваплар:**
**В1 – 3,4,5,6**
**В2 – 3,4**
**В3 – хокукны**
**В4 – бәйләүче сүз (атап әйтсәк)**

# Өй эше

- 73-74 нче биттәге кагыйдәләрне ныгытып килергә;
- күнегү 221;
- “Казаным-башкалам” дигән темага аныклагычлар кулланып бәйләнешле 4-5 җөмлә төзергә.